ТАТАРСТАН ВЕТЕРАНЫ

№ 12
13 декабрь, 2023 ел

РЕСПУБЛИКА ВЕТЕРАННАРЫ (ПЕНСИОНЕРЛАРЫ) ТӨБӘК ИҖТИМАГЫЙ ОЕШМАСЫ СОВЕТЫ ҺӘМ «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» ГАЗЕТАСЫНЫҢ УРТАК КУШЫМТАСЫ

ОСТА КУЛ

Рузилә апа борчуларын пешергәндә оныта

> 5

КЫШКЫ МИЛӘШ

Аның өшегәне файдалырак

> 5

ШӘҖӘРӘ БӘЙРӘМЕ

Нәсел барлау

> 6

Яңа елны каршылап

Безнең көч – бердәмлектә

Хөрмәтле дуслар һәм коллегалар!

Татарстан Республикасы ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасы советы исеменнән, шәхсән үз исемемнән сезне якынлашып килүче Яңа ел белән котлыйм!

Яңа ел алдыннан күңелләребезгә ниндидер тылсымлы хисләр үтеп керә, бик матур теләкләр пәйда була. Бәхет-шатлыкка, уңышка өмет-ышанычлар вәгъдә итүче искитмәле бәйрәм бит ул! Узып баручы ел катлаулы булды. Шуңа да карамастан, дөньядагы яңа сынауларның кырыс шартлары эшчәнлегебезнең тотрыклылыгын какшата алмады. Киресенчә, яңа формалар һәм алымнар белән баеп, ныгыды гына ул.

Өлкән буын вәкилләре өчен бик күп файдалы, изге эшләр башкарылды. Бер генә мөһим эштән дә читтә калмыйбыз. «2025 елга кадәр өлкән буын мәнфәгатьләрендә гамәлләр стратегиясе» кысасында теге яки бу чараларны башлап йөрибез.

Төрле чаралар бик күп өлкәннәрне, республика ветераннар оешмаларының барлык активистларын берләштерде. Шулай итеп, тагын бер тапкыр бердәмлегебезне, эшкә сәләте һәм инициативалы булуыбызны күрсәттек. Башкача безгә эшләргә ярамый да, чөнки ветераннарның социаль яктан үзләрен ничегрәк хис итүләре башлыча нәкъ менә безгә бәйле.

Без «Ветераннар – Татарстанда яшәүчеләрнең мәдәни мирасын һәм көнкүрештәге үзенчәлекләрен саклаучылар» проектын гамәлгә ашыруны дәвам итәбез. Ул эшнең яңа алымнары популярлаштыру өчен зур мөмкинлекләр тудырды. Россия Президенты Владимир Путин 2024 елны «Гаилә елы» буларак игълан итте. Димәк, безгә бу юнәлештә җитди эшләргә туры киләчәк. Без, һәрвакыттагыча, вакыт белән бергә атлыйбыз: эшчәнлегебезнең күп кенә юнәлешләре ата-бабаларыбызның, геройлар һәм гади хезмәтчәннәребезнең истәлеген саклауга багышланган. Узып баручы елда президиумның күчмә утырышлары, Югары Ослангадагы пленумы да, махсус хәрби операциядә катнашучыларга гуманитар ярдәм күрсәтүдә өлкәннәребезнең актив катнашуы да, барыбызның күңелендә бик озакка уелып калачак.

Алдыбызда Җиңүнең 79 нчы еллыгына әзерләнү бурычы тора. Җиңүне якынайту өчен каны һәм тире тамган, сугыштан соңгы елларда фидакарьләрчә хезмәт куйган, бик күп үзгәрешләр һәм реформалар кичергән өлкән буынны игътибарсыз калдырырга ярамый. Безгә – активист-ветераннарга яңа сынаулар алдында тагын да ныграк берләшергә, уяулыкны югалтмаска кирәк. Көчебез – бары тик бердәмлектә!

Яңа ел алдыннан сезгә, кадерле дуслар һәм коллегалар, тагын да күбрәк кызыклы вакыйгалар, яңа үрләр һәм яңа тарафдарлар, бәла-казаларның урап узуын, барыбызның да исән-сау булуын, ә иң мөһиме – өмет-ышанычларыбызның сүнмәвен-сүрелмәвен телим! Татарстан ветераннар хәрәкәтен үстерүгә зур өлеш кертүегез, бетмәс-төкәнмәс көч-энергиягез, бик зур оптимизм рухына ия булуыгыз өчен рәхмәт! Яңа елда һәркайсыбызның хыяллары тормышка ашуын, йортларыбызга иминлек, мәхәббәт һәм тынычлык иңүен телим!

Хәбир ИШТИРӘКОВ,
Татарстан Республикасы ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе

Соклану

103 ЯШЬЛЕК ТАЙФӘ ӘБИ:

«ҖӘННӘТТӘ ЯШИМ»

Саба

Арча районы Ашабаш авылында туып-үскән Тайфә әбигә тормышның ачысын-төчесен күп татырга туры килә. Ул аларны күркәм сабырлыгы белән үткәрә белә.

Ул сугыш чорында кырчылык бригадиры булып эшли. Арчаның ашлык тапшыру пунктына, атка төяп, олау-олау ашлык, бәрәңге ташуларын, Баулыда ач-ялангач килеш окоп казыганда күргән авырлыкларын бүген дә оныта алмый. Сугыштан яраланып кайткан Сеҗе авылы егете Хәбрислам белән гаилә корып, 8 бала тәрбияләп үстерәләр. 1972 елда Шәмәрдәнгә килеп төпләнеп, Тайфә апа мәктәп ашханәсендә пешекче булып эшли. Әбекәйнең йөзеннән нур бөркелә, һәр сүзеннән тормышны яратуы, һәркемгә рәхмәтле булуы, шөкрана кылып яши белүе күренә. Ике улын югалту хәсрәтен дә сабыр гына кичерә ул. Бүген дә биш вакыт намазын калдырмыйча, дини китаплар укып, ил-көнгә тынычлык теләп, игелекле балаларына хәер-дога кылып яши.

– Аллаһы Тәгалә 103 яшьне дә күрергә насыйп итте. Бик күп авырлыклар кичердем, бүгенге тормышым җәннәт, Аллага шөкер. Бервакытта да кешедә булганнан көнсенмәдем, башкалар тормышына кызыкмадым. Кулымнан килгәнчә ярдәмләшеп яшәдем. Озын гомерле булуымның сере, бәлки, шуннандыр. Бәлки, күп бала алып кайтуымнандыр. Аллаһка шөкер, күзләрем дә күрә, хәтерем дә сынатмый әле. Мине – олы кешене хөрмәтләп, ел саен туган көнем белән котлаган район башлыгы Рәис Миңнехановка да зур рәхмәт, – ди ул.

> 5

Оста куллар

БӘХЕТЕ – ЭШТӘН

Апас

Язмышның кырыс җилләренә көчле иңнәрен куеп, балалары хакына бар сабырлыгын җыеп аякка баскан, бүгенге матур тормышына үз көче белән ирешкән батыр хатын-кыз, көчле рухлы ханым, олы йөрәкле ана ул Апаста яшәүче Рузилә апа Фәхретдинова.

Күңеле төшкән чакларда да, еларга сәбәпләр табылганда да йөрәк ярсуларын эш белән, яраткан шөгыльләре белән баскан. Аш-суга да, кул эшләренә дә оста Рузилә апа. Бик яратып гөлләр үстерә. Кыр кадәрле бакчасында да һәр үсемлекнең үз урыны бар. Атна азагында көннәре аеруча да тиз уза. Ул бар дөньясын онытып, тәмле ризыклар пешерә. Балалары, оныклары кайтканда өстәле сыгылып тормаса, күңеле булмый.

«Пешерергә каенанам өйрәтте»

Рузилә апа үзе – Чирмешән авылы кызы. 19 яшендә Иске Әнәлегә килен булып төшә.

– Каенанам Кәүсәрия аш-суга бик оста иде. Кияүгә чыккач, аның янында яшәдем һәм бөтен эшкә дә өйрәндем. Кибеткә йөрергә яратмыйм, барысын да үзем пешерәм, – ди ул.

Күпереп пешкән кабартмалар, өчпочмак, өлеш, бәлешләр, гөбәдия, кош теле, чәкчәк, сап-сары өй токмачы, авызда эреп торган кыстыбыйлар Рузилә апаның тәмле куллы аш-су остасы булуын сөйли.

– Ризыкның сыйфаты оннан да, кәефтән дә тора. Камыр артык майны да яратмый. Бу очракта чүпрәнең кабартырга көче җитми. Беркайчан телләр-теләмәс кенә эшкә тотынганым юк. Камырымның да уңмаган чагын хәтерләмим. Тора-бара остарасың. Беркем дә пешекче булып тумый. Күбрәк иртә белән пешерәм, ул вакытта энергия күбрәк була, – ди Рузилә апа.

Яңашәсендәгеләрне сөендерүдән тәм таба ул. Кая гына кунакка җыенса да, токмачын басып, кыстыбый тышларын пешереп куя. Кучтәнәчләрен төяп бара. Тәмле ризыклар янына бәйләгән башмак, оекбашларын да куя. Буш вакыт калдырмаска тырыша, күңелсез уйларга бирелмәс өчен үзенә шөгыль таба.

– Тормыш иптәшем Минзаһир вафат булганда, миңа 42 яшь иде. Аның ашларына да бар ризыкны үзем пешердем. Борчуларны да эш белән бастым, балаларга күз яшемне күрсәтмәдем, – ди үзе.

Рузилә апа – 4 бала әнисе. Сыңар канат белән калганда, алар әле тормышта үз урыннарын табарга өлгермәгән була. Тырыш, көчле рухлы әниләре ярдәмендә алар югары белем ала, һөнәр үзләштерә, гаилә кора. Бүген инде балаларының, 7 оныгының игелеген күреп, хөрмәтен тоеп яши.

– Балаларым өчен тырыштым, аларны тигез күрдем. Үзләре дә бик тырыш булдылар. Кайталар, киләләр, бар эшемдә булышалар. Хәзер дә алар кайтканда өстәлем тулы сый. Токмач басып та әзерләп куям, – ди ул.

Әнисеннән күчкән шөгыль

Рузилә апаның йортында һәр почмактан нур, чисталык, пөхтәлек бөркелә. Гөлләр шаулап үсә. Күңелендә изге дога йөрткән хуҗабикәнең күңел яктылыгын алар да сизә. Кичләрен Рузилә апа кул эшләренә алына. Башмаклар, бияләйләр, оекбашлар, баш киемнәре, шарфлар, шәлләр бәйли.

– Бәйләү сәләте әнием Гөлсирәдән килә. Ул бик оста куллы иде. Кич белән телевизор каршына утырганда кулыма бәйләү алам. Күзем – телевизорда, кулым эштә була. Тик утырырга иялләшмәгән мин, – ди Рузилә апа.

Кул эшләрен күп итеп әзерләп куя да балаларына, якыннарына, күршеләренә тарата. Бер сыңар бизәкле оекбашны бәйләп куяр өчен бер төн җитә аңа. Яраткан эшенә утыргач, дөнья мәшәкатьләре дә, ялгызлыгы да онытыла.

– Рузилә белән 40 елдан артык күршеләр булып яшибез. Сабыр да, тыныч та, тырыш та ул. Рузилә беркайчан буш кул белән керми. Очрашырга нинди генә сәбәп чыкса да, тәмле ризыклары белән сыйлый, – ди Таһирә апа Шәфигуллина.

Ләйлә ШИҺАБИЕВА

Рузилә апа Фәхретдиновадан кыстыбый җәймәсе рецепты

1 бокал сөткә 1 аш кашыгы шикәр комы, 1 чәй кашыгы тоз, 1 чәй кашыгы күперткеч, 1 аш кашыгы үсемлек мае салабыз. Акрын-акрын он өстәп, камыр басыла. Әзер камырны 15 кисәккә бүләбез һәм җәемнәрне кайнар табада пешерәбез.

103 ЯШЬЛЕК ӘБИ:

«Җәннәттә яшим»

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Гасыр чиген узган мөхтәрәм ананы котларга, өй тутырып, балалары, оныклары да килгән иде. Үндүрт оныгы, егерме оныкчыгының исемнәрен генә түгел, туган көннәрен белүе белән дә сокландыра әле ул.

– Мин 1988 елда бик тәртипле, үрнәк гаиләгә килен булып килдем. Әниең өченче улы Альберт белән матур итеп тормыш итәбез. Ирем – мактаулы тимер юлчы. Мин гомер буе әнидән үрнәк алып яшәдем, күп нәрсәгә аннан өйрәндем. Ул беркайчан беркемгә каты бәрелмәде, балаларына да кычкырып эндәшмәде. Үзем дә киленнәремә әни үрнәген күрсәтәм, – ди килене Вәркыя Әдһәмова.

Тайфә әби сугыш ветеранының тол хатынына дәүләт программасы буенча салынган матур, җылы йортта 77 яшьлек кызы Гөлүсә тәрбиясендә, барлык балалары игелегендә хәерле, матур гомер кичерә.

– Хәзерге көндә үземне бик бәхетле кеше дип саныйм. Әнием белән каракаршы утырып чәй эчүләр дә күңелле. Бер-беребезгә иптәш, терәк булып яшибез, сөйләшеп сүзләр бетми. Бергә пилмәннәр ясыйбыз. Туганнарыбыз килеп көн дә хәлен белеп тора. Дүртебез Шәмәрдәндә гомер итә. Әле тагын озак еллар әни җылысында яшәргә язсын, – ди кызы Гөлүсә ханым.

Фәридә ВИЛДАНОВА

Табигать нигъмәте

Миләш

Миләш согы. Аны ясау өчен, 400 г миләш җиләкләрен изеп, аңа 2 литр кайнаган су һәм бераз шикәр комы салырга, дүрт сәгатьтән соң болгатып, сөзеп эчәргә кирәк. Эч катканда берничә атна буена көнгә өч тапкыр 70–100 грамм шундый сок эчәргә киңәш ителә.

– Азканлылыктан. Ике аш кашыгы кызыл миләш җимешен ике стакан кайнар суга салып, бер сәгать төнәткәч, сөзәргә. Шуны көн буена өч-дүрт тапкыр аз-азлап эчәргә кирәк.

– Үт куыгы ялкынсынган кешеләр дә миләш согының файдасын күрә. Халык медицинасында ул кан басымын нормада тоту өчен дә кулланыла. Моннан тыш, кызыл миләш җиләкләрен изеп, шуңа шикәр комы һәм кайнар су салып болгатып, йоклар алдыннан эчү дә файдалы.

ТАТАРСТАН ВЕТЕРАНЫ
Республика ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасы советы һәм «Ватаным Татарстан» газетасының уртак кушымтасы.
Чыгарылыш өчен җаваплы – **Гөлгенә ШИҺАПОВА**. Биткә салучы һәм бизәүче – **Фәрит ХӘМИДУЛЛИН.**
Безнең адрес: Казан шәһәре, Театр урамы, 5 й.
Телефон: 8(843) 238-16-88
Электрон адрес: soovp.kzn@tatar.ru

ЧАҢГЫ ЮЛЛАРЫ ЧАКЫРА

Азнакай

Ноябрь кары, ниһаять, чаңгыга басарлык калынлыкта һәм, аптырамадым, ихатамның бакча буеннан ак юл салдым. Урыйм да урыйм, мускулларым бик тансыклаган, рәхәтләнеп, яшәрепләр киткәндәй булам.

Аннан тәмле чәйгә кереп утырсам, уйлар йомгагы биләп ала. Нишләп хәзер, мәсәлән, авылларда кыш буе бер чаңгыга басучыны күрмәссең икән. Ә яшь чакларда алай түгел иде бит. Мәктәп буенча, аннары гомуми авыл буенча беренчелеккә чаңгы ярышлары булып, үзе бер спорт бәйрәменә әйләнә торган иде. Ул физкультура дәресләрен көтеп ала идек. Безнең Югары Стәрледә физкультура укытучысы Галимҗан абый Галиуллин һәр баланы, укучыны йөрәге белән тартып ала белә торган бик тә могҗизалы кеше иде. Әйе, бөтенесе укытучыдан тора. Ул совет заманында шушы авылда гына иң киме 200әр бала укый торган агач урта мәктәптә физкультура дәресләре өчен һәммә төр мәйданчыклар төзелгән һәм җитәрлек сандагы чаңгылар да алынган була иде.

Менә шуңа да мәктәбебез чаңгычылары районара ярышларда да гел алдынгы, җитез-өлгерләр иде. Алай гына да түгел, республика – Казанны шаулатканнары да истә. Әле менә шундыйларның берсе булган, Россиягә танылган чаңгычы – авылдашым Мәннәф Сөләйман улы Хөҗҗәтов белән очрашып, фикерләшеп алдык.

– Физкультура һәм спортны кечкенәдән ярата идем, – диде ул. – 4 нче сыйныфта укыганда, беренче мәртәбә чаңгыга бастым. Билгеле, ул чакта чаңгылар хәзерге кебек әйбәт түгел, чабата башына кигереп узыша торган идек. Ә 7–8 нче сыйныфларда укыган вакытта физкультура укытучысы Галимҗан абый Галиуллин спортка мәхәббәт тәрбияләде, физкультура дәресендә үзе чаңгы киеп, безне артыннан ияртеп алып чыгып китә иде. Хәзерге заманда бит нинди генә спорт инвентарьлары юк, авыр чор, дибез, ә юк – спорт өчен һич авыр вакыт түгел. Кайсы мәктәптә физкультура укытучысы чаңгыда үзе алдан әйдәп бара? Хәзерге вакытта күп кенә мәктәпләрдәге физкультура укытучылары очраклы гына кешеләр, ягъни футбол белән волейболны аера алмаганнар дәрес бирә. Минем үземне армия хезмәтенә мәктәбебез, шул мөхтәрәм укытучым Галимҗан абый әзерләде дип әйтә алам. Чөнки ул мәктәбездәге һәр баланы йөгерергә, буйга сикерергә, турникта күтәрелергә әзерләде. Шуңа менә үзем армиягә киткәч тә, безнең Оренбургта хәрби частьта шәһәр беренчелегенә кросста катнашып, өч километр араны йөгереп, икенче булып килдем. Шушы җиңүдән соң миңа карата командирларның карашлары яхшырды. Фиништан соң хәрби мәктәпнең начальнигы полковник Кучер мине тәбрикләп, үзенең «ГАЗ-69» машинасына утыртып алып кайтты. Хезмәт итү срогында 40тан артык грамота алдым һәм спортта ирешкән дәрәҗәләрем миңа югары мәктәптә укырга, аннары Монголиядә эшләргә, хезмәтемне, тормышымны матур итеп алып барырга бик нык булышлык итте.

Әйе, мәктәптә физкультура, аннары спортны даими юлдаш иткән кеше сәламәт яшәү рәвешен үзенең төп кыйбласы итеп куя һәм берчакта да кыенлыклар алдында югалып калмый. Әнә авылдашым СССРның спорт мастеры, күп тапкырлар чемпион исемен яулаган Мәннәф абый да, сигезенче дистәсен узып килгәндә дә, кар төшүгә үк, чаңгысына басып, егетләр кебек җитезлеге белән һәммәбезне сокландыра. Әле дә шәһәребезнең чаңгы базасында яшьләрне дә, өлкәннәрне дә үзе кебек өлгерлеккә өйрәтә.

– Без яшь чакларда һәр авылда ДОСААФның башлангыч оешмалары эшләр иде, хәтта мәктәпләргә кадәр, – ди ул. – Һәрдаим пневматик мылтыктан ату, чаңгыда шуу кебек ярышлар оештырыла иде. Инде хәзер ГТО нормаларын тапшыру да яңадан гамәлдә – һәркайсыбыз да хәрәкәттә булыйк!

Бакчам буендагы чаңгы эзеннән һәр иртәдә кышкы матур көнне каршы алам. Нинди рәхәт саф һава, нинди шифалы илаһи салкынлык. Ә янәшәмдә мәһабәт Чатыртауның әкияти күренеше ачыла…

Әсгать СӘГЫТДИНОВ

ГОМЕРЛЕК МӘХӘББӘТ

Тукай

Күзкәй авылында 54 ел бергә гомер кичерүче Мәгъфия белән Нәкыйп Вәлиевләр бер-берсенә бик охшаган. Үзләренә бу хакта әйткәч, Нәкыйп ага уенын-чынын кушып: «Хатын белән туганлашып беттек. Чынлап та, йөз-кыяфәтебез дә тәңгәлләште бугай инде. Уй-фикерләребез дә уртак», – ди.

Вәлиевләрнең бер-берсенә карата булган җан җылысын күңел күзе белән күрүләре, телне кытыклап торган кинаяле һәм мәгънәле фикерне шаян сүзгә күчерә белүләре һәм шуңа ихластан елмаюлары – зур нигъмәт. Иң мөһиме – алар бер-берсен нечек бар, шулай кабул итә. Ә бу – үзе олы байлык.

Дәһшәтле сугыш еллары үтеп, тыныч тормышта яши генә башлаган елларда якты дөньяга аваз салган Нәкыйп белән Мәгъфиягә дә балачактан ук тормышның кырыс җилләренә каршы торырга туры килә. Икесе дә бар яктан да чыныгып, рухларын ныгытып, буй җиткерәләр. Нәкыйп ага: «Безнең ятим үсүебез дә охшаш», – ди һәм кәләшле булу тарихын кызык итеп искә ала.

– Элек Казан артистлары башкаладан ерак авылларга, юллар сикәлтәле һәм урау булса да, еш кына концерт белән килә торганнар иде. Безнең авылга Габдулла Рәхимкулов концерт белән килде. Клубта алма төшәр урын юк. Шунда күз төште бит менә шушы сылуга. Мәгъфиянең янәшәсендә утырган кыздан матур гына итеп урыннарны алмашуыбызны сорадым. Шуннан озаттым бу чибәркәйне. Армиядә ике ел ярым хезмәт итеп кайткан идем – Ватан алдында бурычым үтәлгән. Җир җимертеп тракторда эшлим. Инде гаилә корсам да була, дип уйладым. Тимерне кызуында сук, дигәндәй, 1970 елның мартында никах укытып, гаилә кордык. Бер уйласаң, ярты гасырдан артык гомер узган, ә ул сизелмичә дә үтеп киткән, – ди, еракта калган яшьлек елларын искә алып.

– Мине әтинең энисе – Мәгъшукъҗинан әбекәем тәрбияләп үстерде. Бала җанлы, миһербанлы кеше булмаса, үз балалары янына ятимнәрне дә сыйдырыр идемени?! Гомере буе бала карап яшәде ул. Иске Байлардан безнең янга килеп, биш ел торды, кызыбыз Земфираны карап үстерде, – дип әбисен сагынып искә ала Мәгъфия ханым. – Сигез класс тәмамлагач, үз авылымда – Иске Байларда сарык фермасында эшләдем, сыер саудым. Егерме яшемдә Күзкәйгә килен булып төшкәч, басуга борчак чабарга йөрдем. Басу-кырларда эш тәмамлангач, фермада сыер савучы булып эшли башладым һәм пенсиягә чыкканчы шул хезмәтемне яратып башкардым. Нәкыйп белән икәүләшеп колхоз эшеннән кайтып кермәдек. Ул чорда колхоздагы бөтен эшне кул белән башкардык. Чатнама суыкларда казан астына ягып, чиләкләп кайнар су алып чыгып, Нәкыйпнең тракторын кабыза идек, – дип искә ала Мәгъфия ханым.

– К-700 дип аталган биниһая олы тракторда да, Т-150К, ДТ-75, МТЗ-«Беларус»та да эшләдем. Колхозда нинди техника бар – барысында да хезмәт куйдым. Техниканы яратканга күрә берсен дә аерып тормадым, – ди Нәкыйп ага.

Чернобыль АЭСында һәлакәт булгач, Нәкыйп ага беренчеләр сафында афәт булган урынга җибәрелә. Типсә, тимер өзәрлек, басса, бакыр изәрлек кырык яшьлек ир-егет радиацияләнгән урында әһәмиятле эш башкара.

– Утыз җиде тапкыр станциягә кердем. Анда зур түгәллек белән эшләү сорала иде. Чернобыльгә киткәнче Оренбург өлкәсендә, Тоцкоеда укыту-өйрәтү курслары уздык. Аллаһы Тәгалә гомерне биргәч яшибез әле. Бал кортлары белән дус булуым сәламәтлек өчен файдага булды, – ди хезмәт ветераны.

Зәрия ВӘЛИЕВА

ОНЫКЛАР БЕЛӘН БЕРГӘ

Балык Бистәсе

Тамырларыңны белү кирәк. Әгәр әби-бабай оныкларга, әтиәни балаларына үз белгәнен өйрәтмәсә, нәселеңне дә белми яшәргә мөмкинсең. Тарихны белү, мәдәниятне барлау, гореф-гадәтләрне саклауда яшь буынны җәлеп итү – иң зур бурычларның берсе. Татарстан ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе Хәбир Иштирәков әнә шулай ди. Нәкъ менә шуны истә тотып, оешма «Шәҗәрәне оныклар белән бергә өйрәнәбез» проектын дәвам итәргә булган.

2019 елда башланган бу эш хәзер республиканың төрле районнарында үткәрелә башлады. Мондый очрашулар Мамадыш, Кукмара районында узган инде. Чираттагысы Балык Бистәсендә иде.

Иң элек районда өлкәннәрнең ничек яшәүләре белән кызыксындык. Шул уңайдан безне «Дельфин» бассейнына алып бардылар. Анда 44 кешедән торган төркем каршы алды. Районның өлкән яшьтәге ханымнары бирегә атнасына өч тапкыр йөриләр. Бирегә килүчеләр белән аралашкач, үзең дә яшәрәсең, ди Балык Бистәсе районының ветераннар советы рәисе Рафаил Шәвәлиев. Ханымнар үзләре дә, картлыкның ни икәнен белмибез, диләр:

– Биредә бушка шөгыльләнәбез. Атнаның бер көнендә фитнеска, ике көнендә йөзәргә йөрибез. Кайберләребез ансамбльләрдә дә чыгыш ясый. Аруның ни икәнен белмибез дә, – ди алар.

Без аларның күнегүләр ясаганын да күрдек. Тренерлары өлкәннәргә туры килә торган махсус күнекмәләр уйлап тапкан. Күбрәк бию рәвешендә шөгыльләнәләр икән.

Ветеран артистлар белән дә танышттык. Районның мәдәният йортына килеп керүгә безне Балык Бистәсенең җырга хирыс, эшкә уңган егет-кызлары каршы алды. Иң элек үзешчәннәр катнашында концерт карадык. Аннары инде кул эше осталары белән таныштык. Балык Бистәсендә – гореф-гадәтләрне саклаучы халык яши. Шәл бәйләүчеләрне генә алыйк! Күгәрчен авылыннан килгән апалар бик матур итеп шәл бәйләү үрнәкләрен күрсәтте. Бәйләп кенә утырмыйлар, яннарында гармунчы егетләре дә бар, рәхәтләнеп җырлыйлар да.

Кул эше остасы Рәмзия Фәттахова челтәр бәйли. Элекке заманнарда Балык Бистәсендә әлеге кул эше дә бик киң таралган булган. Челтәрле бәйләү Россиягә XVIII гасыр башында керә, әмма XVI–XVII йөзләрдә үк инде бездә авыл саен диярлек челтәр бәйләгәннәре билгеле. Казан төбәгендә дә нәкъ шул чорда челтәр бәйли башлаганнар дип исәплиләр. Бездә ике зур үзәк була. Берсе – Балык Бистәсендә. Икенчесе – Мамадыш өязендә. 1887 елда бер Балык Бистәсе авылында гына да 255 челтәр бәйләүче исәпләнә. Мамадыш өязенең Нырты, Әбде, Покровка исемле өч авылында 280 оста челтәр бәйли. Бу саннардан чыгып, әлеге һөнәрнең нинди киң таралыш алуын чамаларга була. Элек кыз балаларны 7–8 яшьләреннән үк челтәр бәйләргә өйрәтә башлаганнар. Челтәр бәйләү 1990 нчы елларда яңадан торгызыла. Челтәрләрне бик сыйфатлы җитен җепләрдән бәйлиләр. Ыргак белән түгел, «коклюшка», безнеңчә әйтсәк, җөй таякчыклары белән бәйлиләр. Рәмзия сөйләвенчә, челтәрнең бизәгенә, катлаулылыгына карап, таякчыклар 300гә кадәр җитәргә мөмкин.

Кул эше осталары янында үз нәселен барлаучы гаиләләр дә бар иде. Алар килгән кунакларга нәсел агачларын күрсәтте. Җиде генә түгел, 14әр буынын эзләп тапкан кешеләр бар монда. Табарсың да. Әгәр һәр авылда бер Нурулла Гариф булсамы? Балык Бистәсенең Яңа Сала авылында гомер итүче язучы Нурулла Гарифның белмәгәне юк. Ул үз районы өчен бик зур эшләр башкарган. Авыл тарихларын барлаган. Әллә ничә китап бастырып чыгарган. Әле дә эзләнүдә. Һәр авылдашының нәселен барлау эшләрен дә башкарган.

Югары Тегермәнлектән килгән Габдрахмановлар да нәсел җепләрен барлаган. Алар язучы Шәүкәт Галиев әсәрләрендәге Шәвәли бабай оныклары икән. 27 ел тарих укыткан Илфар бик күп эзләнгән. Нәселләрне барлый торгач, ярты авылның бер-берсенә туган икәнен ачыклаган. Шәвәли бабайның оныклары икәнен дә белеп сөенгән. Аның сөенерлеге бар: улы Әмир әтисе белән инде ике ел рәттән бабаларын барлый. 8 нче сыйныфта укучы Әмир әтисеннән күпне өйрәнгән.

– Төрле бәйгеләрдә катнашабыз. Миңа әти белән бергә нәселебезне барлау, авыл тарихын өйрәнү ошый, – ди Әмир.

Республика ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасы проектының да төп максаты – буыннар арасындагы элемтә. Бер генә теләк – үткәнне онытмыйк.

– Һәр кеше тарихны белергә тиеш. Нәселеңне белеп, аның гореф-гадәтләрен саклап яшәү кирәк. Без моны яшь буынга тапшырсак иде, – ди Хәбир Иштирәков. – Мондый очрашулар Мамадыш һәм Кукмара районнарында узды инде. Ул районнардагы шәҗәрәләрен барлаучыларның эшләрен кертеп, китап чыгардык. Хәзер ул китапта Балык Бистәсендә яшәүчеләрнеке дә урын алачак. Әлеге китапның авторы – тарих фәннәре кандидаты, доцент, туган якны өйрәнү өлкәсендә Удмуртия Республикасының дәүләт премиясе лауреаты Валентина Хаҗиәхмәтова.

Оныгым белән бергә нәселебезне барладык. Үз мисалымда әйтә алам: бергәләп тотынсак, нәселеңне барлап була. Мөмкинлек булганда, бергәләп эзләнік. Бүгенге тормыш турындагы истәлекләрне киләчәк буыннарга калдырырга кирәк, – ди Валентина Хаҗиәхмәтова.

Үткәнне белмәгәннең киләчәге юк! Балык Бистәсе районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Айгөл Вафина әнә шулай ди.

– Мондый мәгънәле очрашулар бик кирәк. Нәсел җепләрен барлау – зур көч таләп итә торган эш. Ә бит башкарам дисәң, эшләп була икән. Моңа Илфар белән Әмир Габдрахмановлар үрнәк мисал булып тора, – ди ул. – Мондый балалар барда безнең киләчәк өметле!

Гөлгенә ШИҺАПОВА